**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**

**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Совет города Арск**

**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

---

**Арча шәһәре Советы**

# КАРАРЫ

**«11» октябрь 2019 ел** **№ 130**

**Җирле салымнар буенча бурычларны,**
**әлеге салымнар буенча җыелган пенялар**
**һәм штраф бурычларын түләтүне**
**өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының җирле салымнар буенча бурычларны, әлеге салымнар буенча җыелган пеня һәм штраф бурычларын түләтүне өметсез дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турындагы 59 статьясының 3 пункты нигезендә Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар һәм штраф бурычларын (алга таба - бурыч) түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- үлгән физик затлар яисә Россия Федерациясе гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителгән затларның бурыч барлыкка килүе өч елдан арткан мөлкәт һәм җир салымы буенча;
- варислары мирас хокукыннан баш тарткан, варислары булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә варислар тарафыннан мирас алынмаган очракларда, үлгән яисә үлгән дип танылган физик затларның җир һәм мөлкәт салымы буенча;
- салым буенча бурыч һәм (яки) пеня һәм штрафлар буенча бурычлар 2006 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән җир салымы буенча.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы в.б.,
Арча шәһәр Советы рәисе в.б. Г.Х.Нигъмәдҗанова